**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә торак пунктында**

# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“17” ноябрь 2021 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1,56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Түбән Бәрәскә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №116 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә торак пунктында этаплы халык җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылы территориясендә 2022 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә авыл җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Җыелган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Олы Бәрәзә авылы территориясен чистарту (үлән чабу, агач һәм куакларны кисү);

2) урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү (лампочкаларны, үткәргечләрне ремонтлау, алыштыру) һәм лампочкалар сатып алу;

3) зират территориясен чистарту, агач һәм куакларны кисү (килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү);

4) урам юллары өслекләрен ремонтлау һәм төзекләндерү (вак таш сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәт өчен түләү).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең Олы Бәрәзә авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Түбән Бәрәскә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Бәрәскә авыл җирлеге Олы Бәрәзә авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Бәрәскә авыл җирлеге башлыгы: Фатыхова А.В.